**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БОГАДЫ АВЫЛЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ**

423763, ИскеБогадыавылы, Үзәк ур.,
60нчыйорт.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail:sbuq-akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СТАРОБУГАДИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

423763, село СтарыеБугады,
ул. Центральная,дом 60.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«15» декабрь 2025 ел № 24

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
«Иске Богады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча
гомуми тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24,28 статьялары, «Россия Фе-дерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Иске Богады авыл җирлеге Уставы белән Актаныш муниципаль районының Иске Богады авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Иске Богады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча 2025 елның 29 декабренә гомуми тыңлаулар билгеләргә.

2. Гомуми тыңлауларны үткәрү урыны итеп түбәндәге урыннарны билгеләргә:

   -Иске Богады авылы, Иске Богады мәдәният йорты бинасы, адрес буенча урнашкан: Иске Богады авылы, Үзәк ур., 58 йорт, үткәрү вакыты 10:00 сәгать.

   - Яңа Җияш авылы, Яңа Җияш мәдәният йорты бинасы, адрес буенча урнашкан: Яңа Җияш авылы, Г.Тукай ур., 7 йорт, үткәрү вакыты 12:00 сәгать.

- Югары Богады авылы, Каенлык авылы, Югары Богады мәдәният йорты бинасы, адресы: Югары Богады авылы, Урман ур., 20 йорт, үткәрү вакыты 14:00 сәгать.
- Иске Солтангол авылы, Иске Солтангол мәдәният йорты бинасы, Иске Солтангол авылы, Үзәк урам, 42 йорт адресы буенча урнашкан, үткәрү вакыты 18:00 сәгать.
3. Гомуми тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Иске Богады ав., Үзәк ур., 60 й.

4. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Рес-публикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сай-тындагы "авыл җирлекләре" бүлегендә: http:/aktanysh.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.

Башкарма комитет җитәкчесе
Иске Богады авыл җирлеге Р.М.Ахметова